**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
**IV чакырылыш**
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**IV созыва**
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР**
от 18.12.2020 года

**РЕШЕНИЕ**
№05-01

**2021 елга 2022 һәм 2023 елларның планлы чорына Актаныш муниципаль районының бюджеты турында**

**1 статья**

1. Актаныш муниципаль районы бюджетының 2021 елга төп характеристикаларын расларга:
1) Актаныш муниципаль районы бюджетының фаразланыла торган кереме 871 042,71 мең сум күләмендә;
2) Актаныш муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 871 042,71 мең сум күләмендә;
3) Актаныш муниципаль районы бюджеты дефициты 0 мең сум күләмендә.
2. Актаныш муниципаль районының 2022 һәм 2023 еллар план чорына бюджетының төп характеристикаларын расларга:
1) Актаныш муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләме 2022 елга 873 594,01 мең сум һәм 2023 елга 880 272,91 мең сум күләмендә;
2) Актаныш муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме:
- 2022 елга 873 594,01 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 15 455,0 мең сум күләмендә;
- 2023 елга 880 272,91 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 30 835,0 мең сум күләмендә;
3) Актаныш муниципаль районы бюджеты дефициты 2022 елга 0 мең сум һәм 2023 елга 0 мең сум күләмендә.
3. Актаныш муниципаль районының 2021 елга 2022 һәм 2023 елларның план чорына бюджет дефицитын финанслау чыганакларын, әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә расларга.

**2 статья**

1. 2022 елның 1 гыйнварына Актаныш муниципаль районының бурыч йөкләмәләре буенча эчке муниципаль бурычның иң югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә.
2. 2023 елның 1 гыйнварына Актаныш муниципаль районының бурыч йөкләмәләре буенча эчке муниципаль бурычның иң югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә.
3. 2024 елның 1 гыйнварына Актаныш муниципаль районының бурыч йөкләмәләре буенча эчке муниципаль бурычның иң югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә.
4. Актаныш муниципаль районы бюджеты дефицитын финанслау чыганаклары исәбеннән мөмкин булган гарантия очраклары буенча Актаныш муниципаль районы бюджетының муниципаль гарантияләрен үтәүгә каралган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен расларга:
- 2021 елга - 0 мең сум күләмендә;
- 2022 елга - 0 мең сум күләмендә;
- 2023 елга - 0 мең сум күләмендә.

**3 статья**

Актаныш муниципаль районы бюджетында 2021 елга 2022 һәм 2023 еллар план чорына Актаныш муниципаль районы керемнәренең фаразлана торган күләмнәрен, әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

**4 статья**

1. Актаныш муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Актаныш муниципаль районы бюджеты дефицитын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә расларга.

**5 статья**

1. 2021 елга 2022 һәм 2023 еллар план чорына Актаныш муниципаль районы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Актаныш муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен, әлеге карарның 6 нчы кушымтасы нигезендә, 2021 елга 2022 һәм 2023 еллар план чорына бюджет чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләре бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (муниципаль программалар һәм программага карамаган эшчәнлек юнәлешләре), төркемнәре буенча бүлүне расларга.

3. Актаныш муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен 2021 елга 2022 һәм 2023 еллар план чорына бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләренә, бүлекчәләренә, максатчан статьяларына (Актаныш муниципаль районының муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне, әлеге карарга 7 нче кушымта нигезендә расларга.

4. Актаныш муниципаль районы бюджетының 2021 елга гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 8 045,9 мең сум, 2022 елга 8 367,7 мең сум һәм 2023 елга 8 702,4 мең сум күләмендә расларга.

**6 статья**

1. 2021 елга җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен 87 974,1 мең сум, 2022 елга 87 110,8 мең сум һәм 2023 елга 87 229,9 мең сум күләмендә, әлеге карарга 8 нче кушымта нигезендә расларга.

2. 2021-2022 елларга җирлекләр бюджетларына субвенцияләр күләмен 2 498,9 мең сум, 2 525,4 мең сум һәм 2 627,7 мең сум күләмендә, хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга ярашлы рәвештә, әлеге карарга 9 нчы кушымта нигезендә расларга.

**7 статья**

«Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итүче фонд турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү һәм торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итүче фонд чаралары хисабына финанс ярдәме алу өчен, Актаныш муниципаль районы бюджетында, төзелгән килешү нигезендә, күпфатирлы торак йортларны капиталь ремонтлау чараларын тәэмин итү өчен, 1 624,0 мең сум күләмендә бюджетара трансфертларны исәпкә алырга.

**8 статья**

Авыл җирлекләре тарафыннан күчерелә торган башка бюджетара трансфертлар күләмен 2021 елга төзекләндерү өчен чыгым йөкләмәләрен 1 624,0 мең сум, 2022 елга

1 624,0 мең сум һәм 2023 елга 1 624,0 мең сум күләмендә, финанслашу өчен әлеге карарга 10 нчы кушымта нигезендә исәпкә алырга.

Әлеге статьяда күрсәтелгән бюджетара субсидияләр җирле бюджетларда законнар нигезендә җирле үзидарә органнары тарафыннан карала. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы бюджетына авыл җирлекләренә бюджетара субсидияләр күчерүне ай саен тигез өлешләр белән башкарырга.

Җирлекнең җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль районның муниципаль район бюджеты турында муниципаль районның вәкиллекле органының муниципаль район бюджетына бюджетара субсидияләрне күчерү өлешендә карарлары үтәлмәгән очракта, башка бюджетара субсидияләр суммасы, Актаныш муниципаль районының финанс-бюджет палатасы тарафыннан төзелгән финанс-бюджет палатасы тарафыннан акча түләнүгә заявка нигезендә, махсус салым режимнарында каралган салымнар, җирле салымнар исәбеннән алына.

**9 статья**

2021 елга муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләмен 29 900,00 мең сум, 2022 елга 31 500,0 мең сум һәм 2023 елга 31 600 мең сум күләмендә расларга һәм аларны 2021, 2022 һәм 2023 елларга Актаныш муниципаль районының гомуми кулланылыштагы юлларында юл эшләре программасы чараларын гамәлгә ашыруга юнәлдерергә.

**10 статья**

Актаныш муниципаль районының җирле үзидарә органнары 2021 елда муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

Авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарына 2021 елда муниципаль хезмәткәрләрнең һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итмәскә тәкъдим итәргә.

**11 статья**

Актаныш муниципаль районы бюджетында 2021 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертлар 573 985,31 мең сум, 2022 елда - 557 763,01 мең сум һәм 2023 елда - 548 552,31 мең сум күләмендә, әлеге карарга 11 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

Актаныш муниципаль районы бюджетын үтәгәндә әлеге карар белән расланган керемнәрнең гомуми күләменнән чыгып фактта алынган керемнәр, әлеге карарга үзгәрешләр кертмичә, муниципаль бурычны түләүгә, шулай ук аларны үтәү өчен каралган бюджет ассигнованиеләре җитмәгән очракта, Россия Федерациясе Бюджет Кодексының 217 статьясындагы 3 пунктында каралган күләмдә гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерелә.

Әлеге карар белән расланган керемнәрдән тыш, Актаныш муниципаль районы бюджетын үтәгәндә алынган субсидияләр һәм субвенцияләр, әлеге карарга үзгәрешләр кертмичә, җыелма бюджет язмасына үзгәрешләр кертеп, субсидия һәм субвенцияләр бирү максатларына чыгымнарны арттыруга җибәрелә.

**12 статья**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Актаныш районы буенча территориаль бүлекчәсе органы төзелгән килешүләр нигезендә Актаныш муниципаль районы бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне башкара.

**13 статья**

Актаныш муниципаль районы бюджетының калган акчалары - Актаныш муниципаль районы исеменнән төзелгән муниципаль контрактлар өчен 2020 елда шушы муниципаль контрактлар шартлары нигезендә түләнергә тиешле товарлар китерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре суммасыннан артмаган күләмдә, 2021 елда, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан тиешле карар кабул ителгән очракта, күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

**14 статья**

Әлеге карар «Актаныш таннары» газетасында, Актаныш муниципаль районының Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча басылып чыгарга тиеш.

**15 статья**

Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Актаныш муниципаль районы Советы Рәисе** **Э.Н.Фәттахов**